КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 675

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 4 август, 566 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 241 нче; 2017 ел, 28 июнь, 450 нче; 2018 ел, 26 июнь, 520 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче; 2020 ел, 16 июль, 601 нче; 2021 ел, 29 апрель, 297 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1327 нче; 2022 ел, 29 август, 925 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1454 нче; 2023 ел, 18 апрель, 484 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең егерменче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

программаның 3 нче кушымтасындагы «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында» 2013 елның 29 мартындагы 161 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президенты боерыгы» юлының 3 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин